РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«22» февраль 2024 ел г. Альметьевск № 727

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 декабрендәге 1888 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 декабрендәге 1888 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 февралендәге 290 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

1 нче бүлекнең 1 нче пунктының 1.5 пунктчасының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЕЦП - социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа.»;

2 нче бүлекнең 2.6. пунктындагы 2.6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) баланың тууы турында мәгълүмат – ЕГР ЗАГС;

2) никахлашу (аерылышу) турында мәгълүмат – ЕГР ЗАГС;

3) ата булуны билгеләү турында белешмәләр – ЕГР ЗАГС;

4) опека һәм попечительлек органы карарыннан баланы опекага алу турында белешмәләр - башкарма комитет;

5) яшәү урыны һәм булу урыны буенча теркәү исәбе турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;

6) баланың тулысынча дәүләт тәэминатында булуы турында белешмәләр - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

7) фамилия, исем яки атасының исемен үзгәрткән кешеләр өчен фамилия, исем яки атасының исемен үзгәртү турында мәгълүмат – ЕГР ЗАГС;

8) ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында мәгълүмат – ЕЦП;

9) ата-ана хокукларын чикләү турында мәгълүмат – ЕЦП;

10) баланы тартып алу турында белешмәләр – ЕЦП;

11) инвалид турында белешмәләр өземтәсе- Россиянең социаль фонды;

12) хезмәткәрнең һәлак булуы (үлеме), хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә хәбәрсез югалган дип танылуы турында мәгълүмат- Россия Федерациясе Оборона министрлыгы;

13) билгеләнгән пенсияләр һәм социаль түләүләр турында белешмә- Россиянең социаль фонды;

14) күп балалы гаилә статусы турында белешмәләр – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

15) Россия Федерациясе гражданының гамәлдәге паспорты турында мәгълүмат- Россия Эчке эшләр министрлыгы;

16) нотариаль ышаныч Турында мәгълүмат Федераль нотариаль палата.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов